УДК 81 *doi: 10.26907/2658-3321.2020.3.2.105-114*

# ИКЪТИСАДЫЙ ТЕРМИННАРНЫ ИНГЛИЗ ТЕЛЕННӘН ТАТАР ТЕЛЕНӘ НОМИНАТИВ СТРУКТУРА КҮЗЛЕГЕННӘН ТӘРҖЕМӘ ИТҮ ҮЗЕНЧӘЛЕГЕ

***Г. И. Хәсәнҗанова***

*930922.90@mail.ru*

***Казан (Идел буе) федераль университеты, Казан шәһәре, Россия***

**Аннотация.** Халыкара фәнни һәм техник мәгълүмат алмашу соңгы унъеллыкта бигрәк тә артты, ә хәзерге тел, мәгълүмати мәдәният дәрәҗәсен арттыру белән бәйле рәвештә, үсешенең яңа баскычында тора. Икътисади фәннәр өлкәсендә коммуникация алып бару өчен мөһим киртәләрнең берсе – икътисадый терминологияне тәрҗемә иткәндә килеп чыккан кыенлыклар. Тел белән кызыксыну даими рәвештә арта бара; фәнни-техник әдәбият агымын эшкәртү бик кыен булырлык, фәнни һәм техник басмалар саны шулкадәр тиз арта. Чит тел әдәбиятын тәрҗемә итү һәм реферилау белән махсус нәшриятлар, тәрҗемә үзәкләре, фәнни-тикшеренү институтлар һәм профессиональ тәрҗемәчеләр генә түгел, ә хәтта халык хуҗалыгының төрле тармакларындагы белгеч-практиклар да шөгыльләнә. Рецензияләнә торган мәкаләнең актуальлеге берничә телнең (инглиз һәм татар) терминологик берәмлекләрен чагыштырма аспектта тасвирлау зарурлыгына бәйле.

**Төп сүзләр:** чагыштырма конструкцияләр, тәрҗемә, семантика, сүз белеме, номинатив, чагыштыру.

**Сылану өчен:** Хәсәнҗанова Г.И. Икътисадый терминнарны инглиз теленнән татар теленә номинатив структура күзлегеннән тәрҗемә итү үзенчәлеге. Казан лингвистик журналы. 2020; 2 (3):105–114. DOI: 10.26907/2658-3321.2020.3.2.105–114.

# SPECIFITY OF TRANSLATION OF ECONOMIC TERMS FROM ENGLISH TO TATAR LANGUAGE FROM THE POINT OF VIEW OF THEIR NOMINATIVE STRUCTURE

***G.I. Khasanzyanova***

*930922.90@mail.ru*

***Kazan Federal University, Kazan, Russia***

**Abstract.** The international exchange of scientific and technical information has especially grown in the last decade, and the modern language is at a new stage of its development in connection with an increase in the level of informational content of culture. One of the significant obstacles to communication in the field of economic sciences is the difficulty in translating

economic terminology. Interest in language and its knowledge is constantly growing; the number of scientific and technical publications is growing so fast that it becomes incredibly difficult to process the flow of scientific and technical literature. The translation and abstracting of foreign language literature is handled not only by specialized publishing houses, translation centers, professional translators of research institutes and industrial enterprises, but also by practitioners from various sectors of the national economy. The relevance of the reviewed article is due to the need to describe the terminological units of several languages (English and Tatar) in a comparative aspect.

**Keywords:** comparative constructions, translation, semantics, word formation, nominative, comparison, juxtaposition.

**For citation:** Khasanzyanova G.I. Specificity of translation of economic terms from English to Tatar language from the point of view of their nominative structure. Kazan linguistic journal. 2020; 2 (3): 105–114. DOI: 10.26907/2658-3321.2020.3.2.105–114.

Илебезнең Бөтендөнья икътисади берләшмәсенә интеграцияләү шартларында даими рәвештә рус телле укучыларга зур кызыксыну уятучы икътисади тематикага текстлар саны арта. Димәк, лингвистик күзлектән караганда, инглиз телен өйрәнү бик актуаль.

Бүгенге көндә икътисадый тематикага булган терминнарны тәрҗемә итү мөһим бурыч булып тора. Ул бурычны хәл итү адекват тәрҗемәгә юнәлдерелгән. Төрле илләрдә икътисад өлкәсендә эшләгән фәнни хезмәткәрләр арасында мәгълүмат алмашуны тизләтә.

Тәрҗемә телендә күп кенә икътисадый терминнар булмау (бу очракта, татар телендә) бүгенге көндә шулай ук рус һәм татар халкы арасында икътисади тематикага булган коммуникация барышында зур проблема булып тора. Татар телендә икътисади терминология әкренләп бая бара, ә нәкъ менә тәрҗемә текстындагы теге яки бу икътисади төшенчәне белдерү зарурлыгы туганда.

XX гасыр кулланышында актив булган гарәп һәм фарсы телләреннән неологизмнар һәм онытылган алынма сүзләр юлы белән чын-чынлап татар сүзләрен торгызу хәзерге татар телен баетуга ярдәм итә [1]. Яңарыш тенденциясе телнең барлык лексик-тематик өлкәләренә дә кагылып үтте: иҗтимагый-сәяси (*сәясәт*–‘политика’, *инкыйлаб*–‘революция’, *хөррият*–‘свобода’, *тәрәккыят*–‘прогресс’, *җөмһурият*–‘республика’, *хакимият* –‘правление’), белем бирү (*көллият*–‘колледж’, *инша*–‘изложение’), фәнни

(*фәлсәфә*–‘философия’, *назария*–‘теория’), дини (*хам, зәкят*) өлкәләргә. Икътисад өлкәсендә дә яңа лексиканың шактый зур катламы тәкъдим ителгән (*кертемче*–‘вкладчик’, *эшмәкәрлек* –‘предпринимательство’, *икьтисад* – ‘экономика’, *ширкәт*–‘компания’, *сәнәгать*–‘промышленность’, *менеджмент, маркетинг, индексация, бонус, брокер*).

Телнең тулы күләмдә эшләве аның җәмгыять тормышының барлык өлкәләрендә дә катнашуын күздә тота. Татар теленең социаль әһәмиятен рус дәрәҗәсенә кадәр күтәрү-җитәрлек көч, акча һәм вакыт куллануны таләп итә торган гади генә бурыч түгел. Тел куллану өлкәсен киңәйтү – Татарстан Республикасында үткәрелә торган тел сәясәтенең бер юнәлеше. Дәүләт телләрен куллану өлкәләре "Россия Федерациясе халыклары телләре турында" һәм "Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында" дигән законнар белән регламентлана. Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасында бихисап чаралар каралган. Аны куллану өлкәсендә еш кына массакүләм мәгълүмат, Мәгариф, мәдәният, нәшрият эшчәнлеге кебек социаль институтлар бар. Милли телдә эш башкару һәм аның эшләве финанс-икътисад өлкәсендә дә билгеле бер дәрәҗәдә тәкъдим ителә. Финанс-икътисадый терминология аппаратын эшләү, татар телен җәмгыять тормышының иң мөһим өлкәләренә «кертү» – хәзерге заман ике телле җәмгыять алдында торган иң мөһим бурычларның берсе. Шул ук вакытта финанс-икътисад өлкәсендә татар теле әле дә махсус тикшерену объекты булмаган. Моннан тыш, хронологик күзлектән чыгып, тармак финанс-икътисадый лексикасының эшчәнлеге дә тулысынча тикшерелмәгән. Икътисади лексика билгеле бер дәрәҗәдә башка лексик-тематик төркемнәр (рәсми-эшлекле, юридик, иҗтимагый-сәяси) кысаларында яки сүз барлыкка килү һәм чагыштырма типология ягыннан каралды.

Татар теле лексикасы баеп бара, монда неологизм һәм алынма сүзләр роле зур. Икътисади лексика да күбәя бара. Икътисади тематикага багышланган

татар телендә берничә эш бар. Мәсәлән, А. Зарипованың монографиясендә икътисади тематикага булган материал (терминологик лексиканы) рус һәм алман телләрендә чагыштырыла. Г. Калганованың да монографик тикшеренүе бар, ул татар телендә булган финанс һәм бухгалтерия өлкәләрендә эшләп килүче терминнарны җентекләп карый. Шуңа да карамастан, икътисади тематикага каралмаган терминнар күп кала. Мәсәлән, бүгенге көнгә кадәр күп кенә икътисадый терминнарның төгәллеге, семантик үзенчәлекләре һәм номинациянең принциплары билгеләнмәгән. Мәсәлән, хәзерге этапта икътисад үсешенең кайбер мөһим проблемаларын өйрәнмәү татар теленең икътисадый терминологиясен өйрәнү зарурлыгы тудыра, чөнки фәнни хезмәткәрләр һәм галимнәр арасында тикшерелә торган материалның популярлыгы икътисадый терминологияне өйрәнүдә икенче планга чыга.

М.К. Юматованың икътисадый терминологияне чагыштырма өйрәнү өлкәсендә тикшеренү эшләре нигезендә, гомумалтай, төрки һәм татар телендәге сүзләрне аерып чыгару кабул ителде. Борынгы гомумалтай һәм төрки терминнарга *бакыр* ‘медь’, *акча* ‘деньги’, *тиен* ‘копейка’, *алтын* ‘золото’, *алу* ‘покупать’, *сату* ‘продавать’, *аслам* ‘прибыль, выгода, проценты’ һ.б. керә [3].

Европа телләреннән алынган алынма сүзләр арасында иң зур төркемне инглиз теленнән булган алынма сүзләр тәшкил итә, - *инг* кушымчасы бар андый сүзләрдә (*холдинг, рейтинг, буккипинг , дей-трейдинг, демпинг, делистинг, бутстрэппинг, бенчмаркинг, кейтеринг, инвойс-дискаунтинг, клиринг, сэйвинг, ко-маркетинг, факторинг, директор-костинг, валюта демпингы, кире кайту лизингы һ.б.*), шулай ук латин теленнән булган алынма сүзләр (*инфляция, бонус, девальвация, капитализация, конкуренция, кооперация, курс, бифляция, инвестиция, дотация, индексация, экономический конфликт, ликвидность*) [6].

Инглиз телендә икътисадый терминнарын классификацияләүгә терминнарның түбәндәге билгеләре нигез булып тора: эчтәлекле, формаль, функциональ булу. Икътисади терминнарның төп билгесе булып, аларның номинатив билгесе килә.

Инглиз телендә термин барлыкка килү системасында кулланыла торган суффикслар һәм префикслар инглиз теленең гомуми, гади сүз барлыкка китерүче чараларыннан алына. Махсус терминологиянең үзенчәлеге – кайбер суффиксларга билгеле бер терминологик мәгънәләрне беркетергә омтылу [6].

Бу икътисадый терминологиягә гомумән дә хас:

*Administrator* ‘администратор’ – ‘администратор’, ‘идарә итүче’, ‘җаваплы башкаручы’ [5]. *An* ***administrator*** *administers affairs* [8]. *Белемле белгечне бер эшкуар үзенең ресторанына* ***администратор*** *итеп алды. Шулай булганда, рустан гайре милләтләр үзләренең артталыкларына төшенеп, русларны остаз һәм* ***җитәкче*** *сыйфатында ихтирам итәчәкләр булып чыга.* [7].

*Capitalization* ‘капитализация’ – ‘капиталлаштыру, ‘табышлыга әйләндерү’, ‘байлык чыганагы итү’ [4]. ***Capitalization*** *methods are used in the field of Economy* [8]. Акцияләр һәм капиталлаштыру бәясенең кимүе дөньякүләм финанс кризисына бәйле. "Связьинвестнефтехим"ның да төп максаты - әлеге компанияләрне табышлыга әйләндерү [7].

*Cartel* ‘картель’ – картель’ [4]. *In economics, a* ***cartel*** *is an agreement between competing firms to control prices or exclude entry of a new competitor in a market* [9]. *Ул Татарстанның бетон һәм тимер-бетон эшләнмәләр җитештерүче эре заводлары җитәкчеләренә ДТФ белән берлектә чимал белән тәэмин итү мәсьәләләрендә бердәм позиция эшләргә, үзара мөнәсәбәтләр системасын булдырырга бәяләр кую мәсьәләләрендә үз мәнфәгатьләрен саклаган хәлдә,* ***картель*** *килешүе төзергә тәкъдим итте.* [7].

Шулай итеп, бер сүзле икътисадый терминнарны рус теленнән татар теленә тәрҗемә иткәндә бер сүзле, ике сүзле, өч сүзле, дүрт сүзле, биш сүзле, алты сүзле терминнар барлыкка килде:

**Бер сүзле терминнар – (сүзтезмәләр):**

- *карар – resolution* [2] ‘резолюция – имеющее обязательную силу решение акционеров компании’ (карар) [5]. *Draft* ***resolution*** *on promoting the conservation and wise-use of intertidal wetlands and economically-associated habitats is acceptable* [8]. *Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль*

*районының Иске Чокалы авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Иске Чокалы авыл җирлеге Советы* ***карар*** *чыгарды: «...». 1966 елның 19 декабрендә Берләшкән Милләтләр Оешмасының Генераль Ассамблеясы "Космик киңлекләрне, шул исәптән Айны һәм башка күк җисемнәрен тикшерү һәм файдалану буенча дәүләтләрнең эшчәнлек принциплары турында килешү"гә нигезләнгән* ***резолюция*** *кабул иткән иде* [7].

**Ике сүзле терминнар – (сүзтезмәләр):**

- *ышанычлы хуҗа – trustee* ‘доверительный собственник – лицо, которое владеет юридическим титулом собственности, однако не является собственником бенефициаром’ [2] (доверительный – ышаныч белдерә торган, ышанычлы ; 2) яшерен, фаш итәргә ярамаган, сер итеп саклана торган; яшерен рәвештә); собственник – милекче, милек биләүче, хосусый милек иясе, хуҗа; собственник – хуҗа. *Few people really understand what* ***trustees*** *do, so it's very hard to know how to select the right one for when planning your estate* [9]. *Моңарчы сөт җитештерү белән шөгыльләнмәгән* ***ышанычлы хуҗаны*** *өстәмә табыш алу турында да уйлануларга этәрә, ул киләчәктә сауган сөтне сату турында уйлый. Заводка инде дүрт ел* ***ышанычлы хуҗа*** *эзлибез* [7].

**Өч сүзле терминнар – (сүзтезмәләр):**

- *Франциядә профсоюзлар берләшмәсе – syndicate* ‘синдикат – группа, которая принимает на себя страховой риск; каждый синдикат управляется менеджером синдиката или агентом’ [2] (предприятиеләр берләшмәсе; Франциядә профсоюзлар берләшмәсе) [7]. *Branches of Self Certified* ***Syndicate*** *Banks (SCSBs) where* ***syndicate*** */ sub syndicate member submits ASBA form as on April 01, 2017* [8]. *Зеленодольск муниципаль районы флагы җирле үзидарә органнарының утырыш залларында, җирле үзидарә органнарының сайланулы вазыйфаи затларының эш кабинетларында; муниципаль милектә булган* ***предприятиеләр берләшмәсенең*** *булган учреждениеләрдә һәм оешмаларда даими рәвештә урнаштырылган булырга тиеш. Җәй көне "Соцпроф"*

***профсоюзлар берләшмәсе*** *оештырган митингта "Казань – без Метшина!" дигән шагыйрьләр игътибарсыз калды шул* [7].

***Дүрт*** **сүзле терминнар – (сүзтезмәләр):**

*оешманы юкка чыгаручы зат – receiver* ‘ликвидатор – лицо, осуществляющее управление конкурсной массой во всех возможных формах’ [2] (бетерүче, юкка чыгаручы (оешманы, предприятиене) [7]. *All personal property of the Beneficial Owner shall be bound by and subject to all terms and conditions of the Security and further represents and warrants that it has authority to ratify, confirm and authorize the execution and delivery by the* ***Receiver*** *and that there is no agreement, written or oral, whereby it is prohibited or restricted from so doing* [9]. *Зеленодольск муниципаль районында билгеле* ***оешманы юкка чыгаручы зат*** *тарафыннан муниципаль милектә булган предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар таркалына.* ***Предприятиене бетерүче зат*** *булуы факторы басымны арттырган саен, каршы тору көче дә бермә-бер арта, көрәш кискенләшә генә* [7].

**Биш сүзле терминнар – (сүзтезмәләр):**

- *кыйммәтле кагәзьләр җыела, бирелә, саклана торган урын – treasury* ‘Казначейство, министерство финансов’ [2] (казначылык (дәүләт акчасы һәм кыйммәтле кагәзьләр җыела, бирелә, саклана торган урын, учреждение [7]). *The Section 151 Officer will report annually on the adequacy / suitability of the arrangements and will report, as a matter of urgency, the circumstances of any actual or likely difficulty in achieving the Council's objectives in a way of controlling of* ***treasury*** *management risk* [9]. ***Кыйммәтле кагәзьләр җыела, бирелә, саклана торган урыннарда*** *эшне җанландырырга кирәк. Финанс-бюджет палатасы һәм* ***казначылык*** *департаменты коллективлары хисабы палата рәисе Шәмсүн Сөнгатовның бюджет турында шаян доклады һәм ялгыз биюебелән башланды* [7].

**Алты сүзле терминнар – (сүзтезмәләр):**

- *страховка взносларын һәм премияләрне исәпләү белгече – actuary* ‘актуарий’[2]. *In the traditional fields of the* ***actuary****, such as life insurance*

*and superannuation, this rule should not pose any problems* [8]. *As the scope of the* ***actuarial profession*** *broadens it may be necessary to cover this rule by demonstrating how the skills of the actuary relate to the issue at hand* [9]. ***Страховка взносларын һәм премияләрне исәпләү белгече*** *киңәшләре.* ***Актуарий*** *–ул кеше гомерен озак вакытка страховкалау өлкәсендә эшләүче белгеч* [7].

**Полиномнар:**

*Account management department* 'отдел по работе с клиентами' – 'клиентлар белән эшләү бүлеге' [7]. ***Account Management Department*** *profiles is on Linkedin* [9]. *Газетабызда хәбәр ителгәнчә, беренче очрашу Күзкәй авыл җирлегендә үтте, очрашуга Чаллы районара Пенсия фонды идарәсенең Тукай районы бүлеге башлыгы Раил Тимербаев, районара фондның* ***клиентлар белән эшләү бүлеге*** *әйдәп баручы белгеч-эксперты Лариса Федотова килгән иде* [7].

*Accounts payable days outstanding* 'период (срок) погашения кредиторской задолженности'– 'кредитор бурычларны каплауның срогы, вакыты, дәвере'. ***Accounts payable days outstanding*** *measures financing provided by trade creditors to company and management's paying habits* [9]. ***Кредитор бурычны каплауның ахыргы срогы*** *августның икенче декадасына билгеләнсә дә, бюджет средстволарын баш бүлүчеләрне һәм оешма җитәкчеләрен бурычны агымдагы айда каплауларын сорыйм. Иртәнге җидедә* ***кредитор бурычларны каплауның вакыты*** *чыга.* ***Кредитор бурычларны каплауның дәвере*** *– дүрт ел* [7].

Бу эштә башкарылган тикшеренүләргә нигезләнеп, түбәндәге нәтиҗәләр ясарга мөмкин:

1. Терминологияне өйрәнү проблемасы икътисадый текстларны тикшерүдә төп проблемаларның берсе булып тора.

2. Икътисадый терминнар аерым билгеләрдән чыгып, махсус лингвистик классификацияләнергә тиеш. Терминологиянең номинатив характеры: бер компонентлы, ике компонентлы терминнар һәм сүзтезмәләр, өч компонентлы һәм аннан күбрәк терминнар (полиономнар) һәм сүзтезмәләр.

3. Тәрҗемә өчен аерым кыенлыклар булып тора полиномнар.

## Литература

1. Бархударов Л.С. Язык и перевод. Москва: МО. 1975. 240 с.

2. Бизнес: Оксфордский словарь: Англо-Русский: более 4000 концепций. Москва: Издательство РГГУ. 2005. 752 с.

3. Вьюгина С.В. Татарский язык в сфере профессиональной деятельности: учебное пособие. Казань, КГТУ. 2008.151 с.

4. Газизова Ф.М. Русча-Татарча игътисади атамалар сүзлеге. Казан, Раннур. 1999. 448 б.

5. Ганиев Ф.Ә. Русча-Татарча сүзлек. Мәскәү, Инсан. 1997. 718 б.

6. Соколова Т. В. Особенности перевода английских экономических текстов // Социальные и гуманитарные исследования: традиции и реальности. Саранск. 2000. 342 с.

7. Татар теленең язма корпусы // URL: http://corpus.tatar/tt (06.06.2019дан)

8. The Wall Street Journal (19.04.2018). 42 p.

9. The Economist (19.01.2019). 48 p.

## References

1. Barkhudarov, L. S. (1975). *Yazyk i perevod* [Language and translation]. Moscow: MO. 240 s. (in Russian)

2. *Biznes: Oksfordskij Slovar': Anglo-russkij: bolee 4 000 koncepcij*. (2005). [Business: Oxford Dictionary: English-Russian: over 4 000 concepts]. Moscow: Izdatel'stvo RGGU. 752 s. (in Russian)

3. Vyugina, S.V. (2008). *Tatarskij yazyk v sfere professional'noj deyatel'nosti: uchebnoe posobie* [Tatar language in the sphere of professional activity: study guide]. Kazan: KGTU, 151 s. (in Russian)

4. Gazizova, F.M. (1999). *Ruscha-Tatarcha Ikhtisadi Atamalar Suzlege* [Russian-Tatar Dictionary of Economic Terms]. Kazan: Rannur, 448 b. (in Tatar)

5. Ganiev, F. (1997). *Ruscha-Tatarcha Suzlek* [Russian-Tatar dictionary]. Kazan: Insan, 718 b. (in Russian)

6. Sokolova, T.V. (2000). *Osobennosti perevoda anglijskih ekonomicheskih tekstov // Social'nye i gumanitarnye issledovaniya: tradicii i real'nosti* [Features of the translation of English economic texts // Social and humanitarian studies: traditions and realities]. Saransk, 342 s. (in Russian)

7. *Tatar telenen yazma corpusy*. [The written corpus of the Tatar language]. http://corpus.tatar/tt from 06.06.2019. (in Tatar)

8. The Wall Street Journal. (April 19, 2018). 42 p. (in English)

9. The Economist. (January 19, 2019). 48 p. (in English)

**Автор публикации**

***Хәсәнҗанова Гөлнара Илгиз кызы*** *–*
*3нче уку елы аспиранты*
*Казан федераль университеты*
*Казан шәһәре, Россия*
*Email: 930922.90@mail.ru*

**Author of publication**

***Khasanzyanova Gulnara Ilgizovna*** *– third year graduate student*
*Kazan Federal University*
*Kazan, Russia*
*Email: 930922.90@mail.ru*